Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Урта Йорткүл авыл җирлеге Советы

# КАРАР

№ 34 05.10.2021 ел

Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлешендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 15 статьясындагы 4 өлеше, «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлешендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында» 2021 елның 27 сентябрендәге 12-6 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советы карары, «Урта Йорткүл авыл җирлеге Советы карары нигезендә Спас муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» 2019 елның 16 июлендәге 69-3 номерлы Урта Йорткүл авыл җирлеге Советы карары нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Урта Йорткүл авыл җирлеге советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Җирле мәсьәләләрне хәл итү буенча «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләренең бер өлешен Кабул итәргә:

- җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән куллану төренә рөхсәт бирү;

- рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектын реконструкцияләүнең чик параметрларыннан кире кагуга рөхсәт бирү.

2. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Урта Йорткүл авыл җирлеге башкарма комитетына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән тапшыру турында килешү төзүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында (www.spasskiy.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Урта Йорткүл Башлыгы
авыл җирлеге башлыгы: Г. Р. Кәримуллина

СОВЕТ СРЕДНЕЮРТКУЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ